РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» август 2023 ел г. Альметьевск № 2762

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2020 елның 2 ноябрендәге 1601 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген ныгыту, кайнар туклануны оештыру, гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның сәламәтлеген саклау максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2020елның 2 ноябрендәге 1601 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 1906 номерлы, 2021 елның 20 декабрендәге 1879 номерлы, 2022 елның 23 ноябрендәге 2732 номерлы, 2023 елның 20 июлендәге 2397 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Белем алучы инвалид балалар өчен бер укучыга көненә ике тапкыр бушлай туклану бәясе 94 сум 19 тиен, шулай ук ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) язма гаризасы буенча коры паек рәвешендә ике тапкыр түләүсез туклану бирелә (белем алучы инвалид бала стационар (амбулатор) дәваланууда булган очраклардан тыш, ай саен). Бушлай ике тапкыр туклану һәм коры пайкаларны акчалата компенсациягә алмаштыру башкарылмый»;

карарның 1 нче кушымтасының 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Белем алучы инвалид балаларны тукландыру 94 сум 19 тиенгә оештырыла.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

Зак. № 305-2000

3. Әлеге карар 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С. В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов